ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО БИОЛОГИЧЕСКИМ РЕСУРСАМ
ул. Карима Тинчурина, д. 29, г. Казань, 420021

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ БИОЛОГИК РЕСУРСЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ
К. Тинчурин ур., 29 йорт, Казан шәһәре, 420021

Телефон: (843)211-66-94, факс: (843)211-66-47, gkbioresursy@tatarstan.ru, сайт: http://ojm.tatarstan.ru

Приказ | Казан шәһәре | Боерык

14.12.2023 | № 342-од

«Федераль әһәмияттәге аеруча саклаулы табигый территорияләрдәге, шулай ук Россия Федерациясенең Кызыл китабына кертелгән хайваннар дөньясы объектларыннан тыш, хайваннар дөньясы объектларын куллануга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 2018 елның 16 маендагы 126-од номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү буенча эшне камилләштерү максатларында боерык бирәм:

1. «Федераль әһәмияттәге аеруча саклаулы табигый территорияләрдәге, шулай ук Россия Федерациясенең Кызыл китабына кертелгән хайваннар дөньясы объектларыннан тыш, хайваннар дөньясы объектларын куллануга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында» 2018 елның 16 маендагы 126-од номерлы Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты боерыгына (Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 2018 елның 14 ноябрендәге 344-од номерлы, 2019 елның 12 декабрендәге 389-од номерлы, 2020 елның 12 августындагы232-од номерлы, 2020 елның 16 ноябрендәге 350-од номерлы, 2021 елның 12 августындагы 235-од номерлы, 2021 елның 23 сентябрендәге 287-од номерлы, 2022 елның 02 декабрендәге 405-од номерлы, 2023 елның 03

августындагы 225-од номерлы боерыклары белән кертелгән үзгәрешләр белән), преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«Хайваннар дөньясы турында» 1995 елның 24 апрелендәге 52-ФЗ номерлы Федераль законның 6 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең республика органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләрен күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану хакында» 2022 елның 28 февралендәге 175 номерлы карары нигезендә һәм физик һәм юридик затларның мәнфәгатьләрен, Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының структур бүлекчәләренә дәүләт хезмәте күрсәтү эшчәнлеген регламентацияләү һәм стандартлаштыру буенча боерык бирәм:».

2. Боерык белән расланган Федераль әһәмияттәге аеруча саклаулы табигый территорияләрдәге, шулай ук Россия Федерациясенең Кызыл китабына кертелгән хайваннар дөньясы объектларыннан тыш, хайваннар дөньясы объектларын куллануга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган кушымта итеп бирелгән үзгәрешләрне расларга

3. Рәис урынбасарларына, структур бүлекчәләр җитәкчеләренә, дәүләт хезмәтләре күрсәтүне турыдан-туры тәэмин итүче затларга регламентларның нигезләмәләрен үтәүне тәэмин итәргә.

4. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

Рәис Ф.С. Батков

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 2023 елның 14 декабрендәге 342-од номерлы боерыгы белән расланган

Боерык белән расланган Федераль әһәмияттәге аеруча саклаулы табигый территорияләрдәге, шулай ук Россия Федерациясенең Кызыл китабына кертелгән хайваннар дөньясы объектларыннан тыш, хайваннар дөньясы объектларын куллануга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

2.4.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар гариза бирүче тарафыннан шәхсән яки почта аша бирелгән очракта, Рөхсәт яки кире кагу турында карар кабул итү вакыты заявка теркәлгәннән соң 5 эш көне тәшкил итә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар Бердәм порталда, республика Порталында шәхси кабинет аша бирелгән очракта, Рөхсәт яки кире кагу турында карар кабул итү вакыты заявка теркәлгәннән соң 5 ээ көне тәшкил итә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар КФҮгә бирелгән очракта, Рөхсәт яки кире кагу турында карар кабул итү вакыты заявка теркәлгәннән соң 5 эш көне тәшкил итә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар гариза бирүче тарафыннан шәхсән яки почта аша бирелгән очракта, Рөхсәтне гамәлдән чыгару турында хәбәрнамә бирү вакыты гариза теркәлгәннән соң 5 эш көне тәшкил итә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар Бердәм порталда, республика Порталында шәхси кабинет аша бирелгән очракта, Рөхсәтне гамәлдән чыгару турында хәбәрнамә бирү вакыты гариза теркәлгәннән соң 5 эш көне тәшкил итә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар КФҮгә бирелгән очракта, Рөхсәтне гамәлдән чыгару турында хәбәрнамә бирү вакыты гариза теркәлгәннән соң 5 эш көне тәшкил итә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар гариза бирүче тарафыннан шәхсән яки почта аша бирелгән очракта, Рөхсәттән файдалану турында хисап кабул итү хакында хәбәрнамә бирү вакыты хисап теркәлгәннән соң 1 эш көне тәшкил итә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар Бердәм порталда, республика Порталында шәхси кабинет аша бирелгән очракта, Рөхсәттән файдалану турында хисап кабул итү хакында хәбәрнамә бирү вакыты хисап теркәлгәннән соң 1 эш көне тәшкил итә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар КФҮгә бирелгән очракта, Рөхсәттән файдалану турында хисап кабул итү хакында хәбәрнамә бирү вакыты хисап теркәлгәннән соң 1 эш көне тәшкил итә.

Гариза бирүче КФҮгә мөрәҗәгать иткәндә, гариза һәм беркетелә торган

документларны Комитетка Комитет белән КФҮ арасында үзара хезмәттәшлек турында килешүдә билгеләнгән тәртиптә һәм вакытларда тапшыру тәэмин ителә. Хайваннар дөньясы объектларыннан файдалануга рөхсәт бирү яки рөхсәт бирүдән баш тарту процедурасын гамәлгә ашыру вакытына гаризаның КФҮдә булу вакыты һәм дәүләт хезмәте нәтиҗәсен Комитеттан КФҮгә тапшыру вакыты кертелми.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документны бирү гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көндә гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документны гаризада күрсәтелгән элемтә ысулын кулланып (почта аша яки электрон адреска, Республика порталында, Бердәм порталда шәхси кабинетка) җибәрү дәүләт хезмәте нәтиҗәсен рәсмиләштерү һәм теркәү көнендә гамәлгә ашырыла.

Гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ формасында алырга хокуклы.»;

2.4.2 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

3.4 пунктында:

бишенче абзацта «ojm@tatar.ru» сүзләрен «gkbioresursy@tatarstan.ru» сүзләренә алыштырырга;

унынчы абзацта «ojm@tatar.ru» сүзләрен «gkbioresursy@tatarstan.ru» сүзләренә алыштырырга;

ундүртенче абзацта «ojm@tatar.ru» сүзләрен «gkbioresursy@tatarstan.ru» сүзләренә алыштырырга;

3.6.2 пунктның тугызынчы абзацында 2.6.1 саннарын 2.7 саннары белән алыштырырга;

3.6.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура әлеге Регламентта каралган алдагы процедура тәмамланган көнне гамәлгә ашырыла.»;

3.7.2 пунктның тугызынчы абзацында 2.6.1 саннарын 2.7 саннары белән алыштырырга;

3.7.3 пунктының дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура әлеге Регламентта каралган алдагы процедура тәмамланган көнне гамәлгә ашырыла.»;

3.8.2 пунктның тугызынчы абзацында 2.6.1 саннарын 2.7 саннары белән алыштырырга;

3.8.3 пунктының дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар әлеге Регламентта каралган алдагы процедураны тәмамлаганнан соң бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.»;

әлеге Регламентка кушымтада (белешмә) «Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча Дәүләт комитеты» бүлегенең «Рәис» юлының «Электрон адресы» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«gkbioresursy@tatarstan.ru».